# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Бәкер торак пунктында

14 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлегенең Бәкер торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлеге Бәкер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 сум күләмендә билгеләргә:

2. Алынган средстволарны түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

   -җирлекнең су үткәрү мөлкәтен ремонтлау объектларының расланган исемлеге
   -нигезендә, бирелгән вәкаләтләр нигезендә, суүткәргеч мөлкәтен карап тоту;
   - урамнарны яктыртуны оештыру;
   - авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту;
   - авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны вак ташлау;
   - җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Школьная урамы, 15 нче йорт; Бәкер авылы, Нагорная урамы, 38 нче йорт; Ялтау авылы, Тынычлык урамы, 27 нче йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Иске Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Вәлиәхмәтов